**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 16 февралендәге 439 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 10 мартындагы 645 номерлы «Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарны бердәм электрон исемле социаль юл билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынып бетмәгән керемнәрен каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 мартындагы 210 номерлы «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы территориясендә аерым категориягә караган гражданнарга җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2024 елның 18 декабрендәге 3-35 номерлы «2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план

чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 10 мартындагы 645 номерлы «Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарны исемле бердәм электрон социаль юл билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынып бетмәгән керемнәрен каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарның кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5. Субсидия турында белешмәләр Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре төп бүлүчегә җиткерелгән көннән соң 10 эш көне эчендә урнаштырыла»;

1.2. 38 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«38. Субсидия күрсәтү нәтиҗәсе – электрон исемле бердәм электрон социаль юл билетларын (ташламалы транспорт картасы) кулланучы гражданнарның аерым категорияләренә ким дигәндә 1 (бер) юл йөрү күләмендә барлык төр шәһәр җәмәгать транспортында һәм шәһәр яны автомобиль транспортында йөрү мөмкинлеге бирү. Хисап чорында нәтиҗәнең факттагы әһәмияте Казан шәһәренең шәһәр пассажир транспортында йөрү өчен түләүнең автоматлаштырылган системасы агенты хисабы нигезендә билгеләнә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**урынбасар** **И.В.Куляжев**